СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан,
Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы,
ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п.,
Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru,
www.saby.tatarstan.ru

№ _35 от 15.12.2025
На № от

КАРАР

Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 9 апрелендәге 208 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторлары, рәисләр, рәис урынбасарлары, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 16 928 сум күләмендә расларга.»;

**1.2.** Карарга 1 кушымтаны әлеге карарга 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә булачак штат расписаниеләренә үзгәрешләр кертергә.

**3.** Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

**4.** Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**5.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча халыкка җиткерергә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
______________ № ______
номерлы карарына

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасарының, Саба муниципаль районында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисенең акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазифалар атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 44814 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 40334 |
| Депутатлар | 21977 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 18674 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисе | 40334 |